ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, шулай ук алар барлыкка килгән очракта алардан килгән зыян һәм югалтулар күләмнәрен мөмкин кадәр киметүгә юнәлдерелгән чараларны көндәлек эшчәнлек һәм югары әзерлек режимнарында уздыру;»;

2) 21 статьяга түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:
«Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән финанс ресурслары һәм матди ресурслар резервлары, дәүләт матди резервыннан тыш, алардан файдалану әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән резервларны (резерв фондларын) булдыру һәм алардан файдалану тәртибе белән каралган очракта, югары әзерлек режимы кертелгәндә кулланылырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 29 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 21-ТРЗ